**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Центральная, д. 3, с. Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Үзәк урамы, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**“24 “ апрель 2023 ел** **№8**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 07 сентябрендәге 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 21.12.2021 елгы 414-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексын, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге уставын гамәлгә ашыру, Төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү өлкәсендә контрольне көчәйтү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 07 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.7.1 пунктның 7 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яки Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп

итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров